**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 12 » 01 2021 № 02

Аксубаево

Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2020 ел, 13 октябрь, 647 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.11.2010 ел, 880 номерлы карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 26.11.2018 ел, 651 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән һәм «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге, төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләре бирү вәкаләтләреннән тыш, җир кишәрлекләре бирү тәртибе турындагы нигезләмә хакында, яңа редакциядә» 15.12.2020 ел, 22 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»13.10.2020 ел, 647 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Карарның преамбуласында «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 04.04.2013 ел, 111 номерлы карары белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 26.11.2018 ел, 651 номерлы карары белән» сүзләренә алыштырырга.

1.2. 1нче пунктта түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

«1.26. Территорияләрнең кадастр планында җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (26 нчы кушымта);

1.27. Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (27 нче кушымта);

1.28. Шәхси яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядән (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) башка категориягә күчерү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (28 нче кушымта);

1.29. Муниципаль милектәге җирләрдән яки җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты. (29 нчы кушымта);

1.30. Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (30 нчы кушымта);

1.31. Җир участогыннан шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты. (31 нче кушымта);»

1.3. Кушымталар өстәргә: 26, 27, 28, 29, 30, 31 нче.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo. tatarstan. ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С. Ю. Зайцев